Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Кәркәүч авыл җирлеге Советы

# КАРАР

27 март, 2024 ел № 7

Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Кәркәүч авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Кәркәүч торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы Кәркәүч авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кәркәүч авыл җирлеге Уставы нигезендә, Кәркәүч авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 8 апреленә 08 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Кәркәүч торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы Кәркәүч авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Кәркәүч авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Кәркәүч авыл җирлеге Кәркәүч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокլы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 600 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре;

- урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре;

- юлларны кардан чистарту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре;

- Кәркәүч авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре;

- җәен юлларны карап тоту, җәен территорияне чабу, табигый туфракта куаклар һәм вак урманлыкларны төплəү проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре;

2023 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- урам яктыртуны ясау (урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү Кәркәүч авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- торак пункт территориясен төзекләндерү ( юлларны кардан чистарту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре); (җәен юлларны карап тоту, җәен территорияне чабу, табигый туфракта куаклар һәм вак урманлыкларны төпләү проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре);

-

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы: М.Ф.Зәйнетдинов